Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLV-7**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 24 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 24 июлендәге "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турында" гы XX-10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 1 апрелендәге ""Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында"гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 45-ФЗ номерлы, 2001 елның 21 декабрендәге "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" 178-ФЗ номерлы Федераль законнарга таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 24 июлендәге "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турында" гы XX-10 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 13.12.2017 №XXIV-3, 04.09.2018 XXXIII-5 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 5.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

"Шуның белән бергә 5.2-5.5 пунктлары белән күздә тотылган үзидарәлек мөлкәтен хосусыйлаштыру фәкать электрон рәвештә генә гамәлгә ашырыла.";

1.2) 5.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.2. Вәкаләтле орган үзидарәлек мөлкәтен сату буенча функцияләрне мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашыра, шулай ук үзенең карары белән 2001 елның 21 декабрендәге "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" 178-ФЗ номерлы Федераль законның 6 маддәсенең 1 пункты 8.1 пунктчасында күрсәтелгән юридик затларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге хосусыйлаштырыла торган мөлкәтне билгеләнгән тәртиптә милекче исеменнән сатуны оештыруны һәм (яки) андый мөлкәтне сатучы функцияләрен гамәлгә ашыруны йөкли.

Үзидарәлек мөлкәтен сату буенча аукционнар һәм конкурслар нигезләмәсе һәм составы Вәкаләтле орган тарафыннан расланa торган торгиларны (ачык базарларны) оештыру һәм үткәрү буенча даими эшләүче комиссия катнашында уздырыла.".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов